# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге Олы Урсак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

21 ноябрь, 2025 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2025 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта этаплап узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. «2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге Олы Урсак торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнардан һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясе тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту;
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (шул исәптән янгын сүндерү автомашинасын карап тоту);
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, су ташу һәм халыкка су бирү системаларын төзү һәм ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 180 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 97 кеше, бу 54% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен 97 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге Олы Урсак торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге Олы Урсак торак пункты территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнардан һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясе тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау;

- урамнарны яктырту;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (шул исәптән янгын сүндерү автомашинасын карап тоту);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, су ташу һәм халыкка су бирү системаларын төзү һәм ремонтлау.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында, мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Нуреев